# в каждый дом

9 мая 2019 года

## С Днём Победы!




***В девятый день ликующего мая,***
***Когда легла на землю тишина,***
***Промчалась весть от края и до края:***
***Мир победил! Окончена война!***
***Во имя Отчизны – Победа!***
***Во имя живущих – Победа!***
***Во имя грядущих – Победа!***

**Вы только вдумайтесь!**

Если каждого 27 миллионов погибших в Великой Отечественной войне почтить минуты молчания – мир замолчит более чем на 50 лет…

Если все погибшие пройдут парадом памяти – эта колонна будет идти 19 суток…

Гитлеровцы завоевали Францию за 38 дней. В Сталинграде за это время они лишь продвинулись с одной стороны улицы на другую…

Знаменитая Сталинградская мельница – дом Павлова, перед которым фашисты потеряли убитыми больше чем за Европейскую кампанию…

**Такое нельзя забывать!**



Из нашей деревни на фронт ушли 139 мужчин, не вернулись 76 односельчан. Из них 42 — отцы, главы семейств. Остались вдовами 42 женщины, сиротами — 143 ребенка...

*Письмо – стихотворение, адресованное Байгузину Накипу Шарафеевичу фронтовым другом.*

***Пройдут года, придет седая старость,***
***Но память о войне мы в сердце сохраним,***
***Мы не забудем фронтовых друзей, товарищ,***
***Землянки Вислы, Кюстрин и Берлин.***
***И вспомнишь ты, как в городе Познань***
***Мы брали штурмом крепость - цитадель,***
***И как друзья в сраженьях погибали***
***За жизнь, за счастье Родины своей.***

*Германия, Альт – Гольм.*
*30.06.45 год.*

*«Көндәлек тормошыбызда яшәү мәгънәсен аңлап, кешелек сыйфатларын югалтмый, гомер кадерләрен белеп яшәү өчен, халкыбызның данлыклы да, фаҗигале дә булган уткәннәрен онотмыйк!»*

*Ирек Төхвәтуллин.*

## *Бер кем дә, бер нәрсә дә онытылмый!*

1941 елның 22 июнендә сугыш башлангач, барлык ирләр кебек минем Хисмәтулла бабаемның әтисе Гатаулла бабайга да сугышка барырга повестка килә. Ул вакытта Хисмәтулла бабайга 4 яшь, ә апасы Мәрьям апага 5 яшь тулган була. Авылның арысландай ир-егетләре сугышка киткәч, барлык эш хатын-кызлар, балалар һәм картларга кала. Бабайның әнисе Шәмсинур әбигә ул вакытта 27 яшь була. Печән чабу, кибән салу, урак уру, солы чабу, чәчүлек җирләрен чоку – болар барысы да хатын-кызларга кала. Алар сыер белән сабан сөрәләр, көнбагыш, бәрәңге җирләре чокыйлар. Һәр кешегә 50 сутый җир казырга план бирелә. Ашарга булмый. Бәбәк ашы, имән бөресе, кузгалак, кукы, куян тубыгы ашап яшиләр. Иң тырышып урак урганда да ике кашык он бирә торган булганнар. Ничек тә тамак туйдырырга кирәк бит. Моның өчен әбиләр эштән соң бер телем ипи өчен кешегә бәрәңге җире казыганнар.

Яз көне Богдан кысыгындагы юлны калын боз катламы каплаган. Моны ваткан өчен һәр кешегә ипи бирелә. Бу ипи өчен ике кубометр җирне чистартырга кирәк. Әлбәттә, бик җиңел эш түгел. Утынны урманнан сөйрәп алып кайтып ягырга кирәк. Аның бер өлешен ипи өчен саталар. Угез белән чыбык ташыйлар. Бу чыбыкны сыдырып, фермага тапшыралар: һәр семьяга план буенча 40 кг. Бабай әнисе Шәмсинур әби белән чыбык ташый, ә Заһит абый, Мәрзия һәм Мәрьям апалар сыдыра. Кыш көне кырда калган башакны чокып, уалап ашыйлар. Балалар ачтан үлмәсен дип, Шәмсинур әби бер сарык, бер кәҗә төяп ридуанга үгез җигеп Бәрдәш ягына алып барып ипигә алмаштыра. Менә шундый ачлыкта яшиләр.

Моннан тыш колхозга май, сөт бирергә кирәк. План – 9 кг май, 50 кг ит. Җигеп сабан сөргән сыердан ничек 9 кг май аласың инде? Шуның өстенә тагы 1 сыерга карап торган дүрт бала...

Гатаулла бабайның хаты килә. “Курск дугасы ягында иң каты сугышка керәбез, тере калсам, хат язырмын”,- дип язган була. Ләкин аның хәбәрсез югалуы турында кәгазь килә. Хат һәм хәбәрсез югалу турында кәгазь, кызганычка каршы, сакланмаган.

**Данил Кинҗәгулов,**
**9 – нчы сыйныф укучысы**

## *Сугыш чоры балалары хәтерли...*

Сугыш башланганда миңә 3, ә Мирхәт абыема 5 яшь иде. 3 яшьлек баланың күңелендә нык истә калган мизгеле була диләр бит. Минем дә абыйның тышта уйнап йөргән вакытта кайдандыр ишетеп кереп, “Сугыш килгән” дигән сүзе колап төбемдә әле дә яңгырап тора кебек. 3 яшьлек сабыйга ул коточырлык сүз аңлашылмагандыр да, тик менә әтинең безне, ике баласын, үбеп саубуллашып чыгып китүе нык исемдә калган.

Ирләре, уллары сугыш кырында ач булмасыннар өчен, көнен көнгә ялгап, әниләр алсыз-ялсыз яланда булдылар. Савыла торган сыерларын, үгезләрне сабанга тагып сөреп, чәчә торган барлык культураларны да чәчә торган иделәр. Чәчердәй бер җир дә чәчелми калмый иде. Ә инде көзен җыелмый калган булмый иде. Әниләребез, яңа туган балаларына хәтле бишекләр белән алып китеп, яланда урак белән иген урдылар. Ә без, 3-5 яшьлек балалар, аналары килгәнче бишек тибрәтәбез, ә малайлар ашарга әзерләү өчен учакка чыбык-чабык хәстәрлиләр. Шуңа мин дә үзем кечкенә булсам да, диңгез суының бер тамчы суы кебек булса да, җиңү өчен үз өлешемне керткән кебек хис итәм. Әниләргә ияреп учакта таба белән куырмач куырып тамак туйдырабыз, анысы да бригадир апа күрмәгәндә генә, күрсә – эш харап, әнигә сүз тия. 2 кг ашлык сораусыз өчен дә хәтта төрмәгә япканнар. Законнар каты булган. Минем уемча, сугыш чоры законнарының каты булуы бик урынлы булгандыр. Әйтәләр бит “Тамчыдан күл җыела” дип.

Сугыш беткәч тә бик үк җиңелдән булмады без кечкенәләргә. Көздән торып калып, язга шыртып агуланып яткан бодайларны ашап үлүчеләр дә аз булмады. Ярым-ялангач аяктан абыйга бәрәңге басуыннан черек бәрәңге җыеп алып кайтырга ярдәмем тия иде. Ә әни безгә бәрәңге коймагы ашата иде...

Мин хәзер олы яшьтә. Үзебез күрсәк тә, балаларым сугыш күрми үстеләр. Инде оныкларым гына без күргән газапларны күрмәсеннәр дип, Ходайдан сорыйм. Без сугыш теләмибез.

**Тукаева Флүрә апа (Флүрә әбиегез).**


| | | | |
|---|---|---|---|
| **Редактор: Л.К. Тухватуллина**<br>**Технический редактор**:<br>**Р.Р. Рашитов.** | Издатель: МОБУ СОШ им. Н. Каримова с. Кугарчи<br>Адрес: 453383, Республика Башкортостан, Зианчуринский район, с. Кугарчи ул. Центральная 47а | **Газета выходит два раза в месяц**<br>Читайте нас на сайте http://kugarchi.bryanschool.ru/ | Подписано в печать: в 8:00 ч. 09.05.2019 года.<br>Объем издания 1 печ. л.<br>**Тираж 100 экз.** |